РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ШИКШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422053, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Шикши, ул. Школьная, д.4
тел. (84362) 46-1-35

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЕКШЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422053, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Шекше авылы, Мәктәп урамы, 4 йорт
тел. (84362) 46-1-35

e-mail:Shik.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
25.02.2021 ел

КАРАР
№ 6

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, шулай ук җирлек территориясендә төзекләндерү объектларын карап тотуга, чисталыкка һәм тәртипкә карата бердәм таләпләр билгеләү, тулаем алганда төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Советының 2017 нче елның 7 нче ноябрендә кабул ителгән "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында " 23 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 196.1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Учреждениеләр такталарыннан һәм режим табличкаларыннан тыш, тышкы мәгълүмат чаралары, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты белән килештерелгән паспорт нигезендә һәм аңа тулысынча туры китереп урнаштырыла һәм эксплуатацияләнә.»

1.2. 198 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«198. Грунтны ачу яки юл катламнарын каплау (җир асты коммуникацияләрен салу, реконструкцияләү яки ремонтлау, свай һәм шпунтны сугу, электр тапшыру, элемтә, ут баганалары урнаштыру (алмаштыру), грунтны планлаштыру, инженерлык эзләнүләре вакытында эшләү һәм башка эшләр) белән бәйле эшләр бары тик Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан бирелгән язма рөхсәт булганда гына башкарыла.»;

1.3. 199 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«199. Торак пункт территориясен төзекләндерү белән бәйле Җир, төзелеш һәм ремонт эшләрен оештыру һәм үткәрү тәртибе, җир эшләрен башкаруга ордер рәсмиләштерү һәм алу Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарының хокукый актларының билгеләнгән таләпләре нигезендә башкарыла»;

1.4. 200 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«200. Агач һәм куакларны кисү, төпләү яки утырту кирәк булганда, авыл җирлеге Башкарма комитетының агач кисү, төпләү яки утырту өчен рөхсәтен билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерергә кирәк.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

Авыл җирлеге башлыгы Хәйртдинов Р.Р.